ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2020 елның 23 гыйнвары** **Чистай шәһәре** **№ 27**

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Башкарма комитеты тарафыннан
2019 елның 08 февралендәге
59 номерлы карары белән расланган,
Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Башкарма комитетының
торак-коммуналь хуҗалык,
төзелеш, транспорт, энергетика,
элемтә һәм юл хуҗалыгы бүлеге
тарафыннан муниципаль контрольне
оештыру һәм гамәлгә ашыру
функцияләрен үтәүнең административ
регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Чистай шәһәре прокурорының 2020 елның 14 гыйнварындагы 02-08-02-2020 номерлы протестын үтәү йөзеннән, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында»гы 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон белән, «Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясындагы 1 өлешенең 4.1 пунктында каралган планлы тикшерүләрне ел саен үткәрү планына кертү өчен нигез өлешендә Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 2 декабрендәге 390-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 08 февралендәге 59 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының торак-коммуналь хуҗалык,

төзелеш, транспорт, энергетика, элемтә һәм юл хуҗалыгы бүлеге тарафыннан муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру функцияләрен үтәүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. II бүлек 2.2.п. 1.п.п. "Функцияләрне башкару тәртибенә таләпләр" түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1п.п. 2.2.п. - торак милекчеләре ширкәте, торак, торак-төзелеш кооперативы, яисә күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы тарафыннан күрсәтелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыра башлау турында дәүләт торак күзәтчелеге органына тапшырылган хәбәрнамә нигезендә гамәлгә ашырыла башлаган көннән алып бер ел узгач.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый мәсьәләләр буенча беренче урынбасары Л.Х. Кашаповага йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов